**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАРЫ**

2018 елның 30 ноябре 17№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Иске Камка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставы нигезендә 2018 елның 19 ноябрендәге 25 номерлы «Җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге гражданнарының кушымтада бирелә торган үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ТР Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Ә.Акберов

Иске Камка авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 30
ноябрендәге 17
номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү киләсе календарь елның 1 гыйнварына кадәр җирле референдумда катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә Иске Камка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, 18 яшькә җитмәгәннәр, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 18 яшькә җиткән барлык гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына Иске Үргәгар авылы, Иске Үргәагар һәм Яңа Ургәагар авылы мәгълүмат стендларында һәм Әлки муниципаль районы http://www.alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтының Иске Камка авыл җирлеге битендә басылып чыгу һәм халыкка игълан итү юлы, шулай ук кәгазьдә имзалатып тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллама белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) башкаруга исәп-хисап ясау хокукына ия оешма аша яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы аша акча күчерү юлы белән башкарыла

6.Түләү фактын касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар раслый.

7. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Иске Камка авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 30
ноябрендәге 17
номерлы карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ______ №

Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
__________________________________________бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)

Түләүченең Ф.И.О. __________________________________________________

Адресы: ____________________________________________________________

Нигездә:____________________________________________________________

Сезгә бер тапкыр түләнә торган түләүне________________________ вакыты җиткәнче түләргә кирәк

_______________________________________________ сум күләмендә

реквизитлар :__________________________________________________________

Алучының банкы БИК ________________________________________

Сч. № ____________________________________

Алучы Сч. № ____________________________________________

ИНН _____________________________________________

КПП _____________________________________________

КБК _________________ ОКАТО ___________________

Түләү билгеләмәсе

__________________________________________________________________________

___________________________________________________________________

Җитәкче ___________________ ________________________

М.У. (имза) (имзаны җәелдерү)

**кисү линиясе-** - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә № ___________________

Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне

____________________________________________бюджетына түләү турында

(муниципаль берәмлек исеме)

суммада ___________________ сум.

Түләүче Ф.И.О. ____________________________________________________________

Адресы: _______________________________________________________

Алдым 20___ ел. "__" ___________________ ________________________

(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Киселгән өлеше хәбәрнамә тапшырылса, тутырыла һәм Иске Камка авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*